**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 7 декабрь № 903

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри нөсхәсен Татарстан Республикасының аудиовизуаль документлар үзәк дәүләт архивына кертү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 3 октябрь, 823 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри нөсхәсен Татарстан Республикасының аудиовизуаль документлар үзәк дәүләт архивына кертү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 3 октябрь, 823 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 27 июнь, 467 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «Татарстан Республикасының аудиовизуаль документлар үзәк дәүләт архивына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә» сүзләренә алмаштырырга;

1 һәм 2 нче пунктларда «Татарстан Республикасының аудиовизуаль документлар үзәк дәүләт архивы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе» сүзләрен «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Аудиовизуаль продукциянең мәҗбүри нөсхәсен Татарстан Республикасының аудиовизуаль документлар үзәк дәүләт архивына кертү тәртибе (алга таба – Тәртип) исемендә «Татарстан Республикасының аудиовизуаль документлар үзәк дәүләт архивы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 1.1 нче пунктында «Татарстан Республикасының аудиовизуаль документлар үзәк дәүләт архивы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\903.doc